| | |
|---|---|
| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО<br>ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ИВАНОВСКОЕ<br>СЕЛЬСКОЕ ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>«ИВАНОВКА<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 елның 25 феврале Ивановка № 3

2017 елның 13 ноябрендәге 83-ЗРТ номерлы «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Законын үтәү йөзеннән, «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1 Ивановка авыл җирлеге Башкарма комитеты Башлыгының «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау хакында» 2018 елның 19 сентябрендәге 10 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

а) 1 пунктта «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башлыгының «Административ беркетмәләр төзергә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында» 2018 елның 19 сентябрендәге 10 нчы номерлы карарындагы кушымтада «2.2» һәм «2.7» сүзләрен төшереп калдырырга;

в) таблицада «Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.2 статьясы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы/ “Ивановка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (секретаре)»; - “Ивановка авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) таләпләрен үтәмәү һәм "Татарстан Республикасы Административ хокук бозулар Кодексының 2.7 статьясы муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларын куллану тәртибен бозу/ «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль

берәмлеге Башлыгы; - «Ивановка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары (сәркәтибе) сүзләре кергән юлларны төшереп калдырырга.

2. Административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә вәкаләтле затларның вазыйфаи инструкцияләренә үзгәрешләр кертергә, кушымта нигезендә.

3. Әлеге карарны Ивановка авыл җирлегендәге мәгълүмат стендларында бастырып чыгарырга һәм “Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

“Ивановка авыл җирлеге”
муниципаль берәмлеге башлыгы А.П. Бодряева